КАРАР (РЕШЕНИЕ)

"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15.11.2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 3нче, 7нче, 8нче, 9нчы, 10нчы сентябрь көннәрендә «Сез 2023 нче елда "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе" муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең тышкы яктырту челтәрләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү буенча эшләр башкару;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең су агу улакларын төзекләндерү һәм ремонтлау;
- Байлар Сабасы бистәсендә һәйкәлләрне ремонтлау;
- Байлар Сабасы бистәсендә тротуарларны ремонтлау һәм төзү;
- Байлар Сабасы бистәсендә паркларны, яр буйларын, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, халыкның күпләп ял итү урыннарын карап тоту, төзү, ремонтлау һәм паркларны яктырту;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы җирләү урыннарын төзекләндерү соравын үз эченә алган узган җыеннар нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 6463 катнашучы кертелгән, шуның 3264се тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 3115 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 149 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы бистәсе торак пунктында халык җыенын үткән дип, аның нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Сез 2024 нче елда "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе" муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара

салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең тышкы яктырту челтәрләрен төзү, реконструкцияләү, капиталь төзекләндерү буенча эшләр башкару;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең су агу улакларын төзекләндерү һәм ремонтлау;
- Байлар Сабасы бистәсендә һәйкәлләрне ремонтлау;
- Байлар Сабасы бистәсендә тротуарларны ремонтлау һәм төзү;
- Байлар Сабасы бистәсендә паркларны, яр буйларын, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, халыкның күпләп ял итү урыннарын карап тоту, төзү, ремонтлау һәм паркларны яктырту;
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы җирләү урыннарын төзекләндерү карарын кабул ителгән дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Саба шәһәр
җирлеге башлыгы урынбасары Л.Р.Фәйзетдинов